ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.10.2020 с. Набережные Моркваши 9

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Покровка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020нче елның 7нче ноябрендә 9 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлеге Покровка авылында гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020нче елның 7нче ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлеге Покровка авылында гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Покровка авылының Үзәк урамында яшәүчеләр.

2 этап: Покровка авылының Фурцев урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслarga:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваш авыл җирлегенең Покровка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

- Покровка авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау
- Покровка авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Покровка авылының Үзәк урамы буенча 19нчы номерлы йорт янында

2 этап: Покровка авылының Үзәк урамы буенча 216нчы номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов